**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 10 ноябре** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Оча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 22 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Оча авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Оча авылы, Беренче май урамы, 21 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 22 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Оча авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Оча авылы, Беренче май урамы, 21 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Оча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Иске Оча авылы юлларында чокырларны ямау; проект-смета документлары;; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- урам утларын карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү);
- Иске Оча авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Түбән Үрәс авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы В.Г.Сафаров